# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Коры Көрнәле авыл торак пунктында
2024 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2023 елның 12 октябреннән** **№ 2**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Коры Көрнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елда Алексеевск муниципаль районының «Көрнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Коры Көрнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- торак пунктта урамнарны яктыртуны карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Коры Көрнәле торак пунктының Татарстан урамы юлларын төзекләндерү (юлларга таш җәю,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- күмү урыннарын карап тоту һәм төзекләндерү (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- суэтем манарасы өчен су насосын алу;
- каты көнкүреш калдыкларын җыю өчен контейнер мәйданчыгы урнаштыру (төзелеш материалы алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Көрнәле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

2. Әлеге карарны Көрнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Көрнәле авыл җирлеге башлыгы — Казакова Д.Б.